Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ГЫЙНВАР * 2022 * КАЗАН

1



Александр АЛЁШИН

ГАЕП ИТМӘГЕЗ – КҮҢЕЛНЕ ЮАТЫП КАЙТТЫМ

Нинди дә булса нәрсәне йөз мәртәбә ишеткәнче, бер мәртәбә күрүең хәерле дигәнрәк гыйбарә бар.

Минем олы кызым Фәридә инде ун елдан артык Мәскәүдә яши. Миңа ел саен анда барырга туры килгәли. Рәхәт инде почетлы кунак булып ятулары!

– Йә, әти, кая барасың, нәрсә күрәсең килә? – диләр.

– Әйдәгез, – мәйтәм, – бүген үк Мәскәү Кремленә барыйк әле?

– Анда керү түләүле икән бит әти, – диюләре була, мин:

– Минем кебек хезмәт ветеранына бушлай ул! – дип җиппәрәм, киерелеп, күкрәк кагып.

Шулай, кияү белән кыз һәм оныгым да минем аркада рәхәтләнеп илебезнең үзәгендә йөреп чыктылар.

– Син алып кермәсәң, гомергә мондый матурлыкны күрү тәтемәгән булыр иде, – дип сөенәләр.

– Ә кәк же! Әтиегез исән чакта кулланып калыгыз яхшылыгымны! – дим.

Йөрибез шулай мәйданда... Бер кызыл бина капкасы янында күрәм – Ленин белән Николай патша басып тора. Ленин – үзенчә, патша – үзенчә киенгән... Яннарында – ике сакчы. Ленинны штык тоткан кызылармеец саклый. Килдем дә, Ленин белән күрешеп:

– Нәрсә, – мәйтәм, – Владимир Ильич, патша хәзер синең дустыңмыни? – дим.

Ул инде үзенчә "р" хәрефен акцент белән җавап бирә:

– Менә дуслаштык әле, Рәсәйне кризистан чыгарып булмасмы дип? – ди.

Мине ерактан оныгым видеокамерага төшерә икән. Боларга – патша һәм юлбашчыбызга уңышлар теләп, киттек алга таба.

Мәйданда бер әби йөри.

– Әби, – мәйтәм, – сезне кем дип белим, – дим.

– Мин, әфәндем, патша Екатерина II булам, – ди. Аерып ала торган түгел – шул формага киенгән.

Ә мин әйтәм:

– Сезне хәтерлибез, сез Казан өчен зур изге эш эшләдегез! Явыз Иван Казанның бөтен мәчетләрен җимереп бетергәч, безгә мәчетләр салырга рөхсәт биргән идегез. Сез утырып йөргән арба музейда әле дә тора, ә копиясе – Проломная урамында. Ул да шулай ук шунда йөреп акча эшли икән.

Шул тирәдә генә, әвеш-тәвеш килеп, бер исерек йөри. Монысы – Распутин булып чыкты. Янына бармадым инде, йә акча сорар...

Аннан Мавзолейга Ленин янына кердек, анда ун метрлап аска төшәсе. Сыек кына яктылык. Минем тел тик тормый бит инде:

– Владимир Ильич, – мәйтәм, – торыгыз әле, тагын безне дөрес юлга кертегезче! Без Сез күрсәткән юлдан адаштык, ахрысы, – дим.

Ә халык әкрен генә көлә.

Көлер шул: елап туйгандыр инде. Халык сүзен тыңлаучы юк хәзер, Ильич янына кереп кенә зарланып чыктым. Гаеп итмәгез!

Сөләйман ШАКИРОВ,
хезмәт ветераны, II төркем инвалид.

КАЗАН

Эрнест ДЫШАЕВ, «Чаян» № 12, 1999



Герман ОГОРОДНИКОВ, «Чаян» № 7, 1995



Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Яңа елга – яңа хыяллар

Менә Яңа ел да җитте. Нәрсәләр көтә икән безне? Хыяллар күп. Барысына да ирешеп булыр микән?

...Моннан берничә ел элек йортыбызның соңгы кат тәрәзәсеннән Югары Ослан якларына карап тордым. “Менә быел шунда барырбыз. Балалар телефоннарына гына терәлеп утырмасын, бераз саф һавада йөрсеннәр”, – дип уйладым. Уйларым уй булып кына калды. Эш күп, вакыт җитми. Ял көне өйдән чыгасы килми, ирендерә. Шулай ул ел узып китте.

Икенчесендә, Кремль якларын күрсәтеп кайтасы килде. Шәһәр матурайган, үзгәргән, диләр. Инде балалар да үсеп җиткән, күрсәтеп кайтыйм әле, дигән идем. Бер-ике елдан алар минем белән үзләре дә йөрмәс. Тагын вакыт табылмады.

– Балалар, – дим, – киләсе елга нинди планнар корабыз? Кайларга сәяхәт итәрбез икән?

– Әни, – син безне инде урманга да алып барырга сүз биргән идең, шәһәрне карап кайтырбыз дип тә өметләндергән булдың... Бардыкмы соң?

Утыра торгач:

– Әйе, әни, без мәктәптә Габдулла Тукай шигырьләрен өйрәнгәндә, син Кырлай турында сөйләдең. Шунда барырбыз, дидең. Бармадык, – дип үпкәсен белдерде кече улым.

Миңа чамадан тыш уңайсыз булып китте.

– Чыннан да, балалар, бу өй эшләре бетәрдәй түгел. Бара торган җирләр күп. Театрга да, музейларга да, урманга да барырбыз. Телевизор каршында яки телефон белән гомерне бушка уздырырга ярамый.

Яңа елда яңа тормыш башларбыз!



• • •

Автостанция хуҗасы үзенең бай клиентына шалтырата:

– Алло, Гафур әфәнде! Әле генә машина белән сезнең кызыгыз килеп керде. Шуны ачыкламакчы идем, ремонт чыгымнарын сез түлисезме?

–Машина ремонтлаган өченме? Әлбәттә!

– Гафу итегез, ләкин сүз станцияне ремонтлау турында бара...





Күңелгә җылы бирүче сыекчаларга халкыбыз мөнәсәбәтен төрле сәбәпләр белән аңлаталар. Берәүләре моны кырыс климат һәм еш кабатлана торган җан газаплары дип саный, икенчеләре исә хәмердән тирә-юньдәге тормышны кабул итү җиңеләя дип уйлый. Әмма тегеләре дә, болары да бер нәрсәдә уртак фикергә килә: эчкәннәр, эчәләр һәм эчәчәкләр. Илебезнең чиксез киңлекләрендә эчүгә ниндидер уңай юнәлеш бирергә тырышулар халыкның аңламавына бәрелеп челпәрәмә килде. Эчемлекләрнең затлысын чама белән генә эчүнең гүзәллеген күрсәттеләр шикелле, ләкин аның өчен акча бирмәделәр, һәм халык сукмагы матур кибет киштәләрен читләтеп, элеккедән таныш – өйдә куылган арзан көмешкәгә таба юнәлә. Ә нәрсә – нәтиҗәсе бер үк булгач, нигә артыгын түләргә?

Ләкин статистика башка нәрсә күрсәтә. Татарстанда, мәсәлән, шикле алкоголь белән агулану очраклары узган елның беренче яртысында гына бермә-бер артты һәм 448 гә җитте.

Менә бу ямансу статистикадан бары берничә вакыйга. Берзаман Казанда ике дус тамак чылатып алырга булганнар. Бу "бәйрәм" озакка сузылган, һәм алар җылы әңгәмә белән һәр эчкечегә таныш мизгел – кечкенә 10 тулуын сизми дә калганнар. Җаннар дәвам даулый башлагач, алар таныш "төнге нокта"га юнәлгәннәр. Ә берникадәр вакыттан токсиколог табиблар кулына барып кергәннәр.

Ә Чаллыдагы бер хәмер сөюче япа-ялгызы кәеф күтәрүне артык күргән. Акчаны янга калдыру максатыннан, ул исерткеч сыекчаны иҗтимагый челтәр аша сатып алган. Аракы беркайчан да артык булмый дигән гыйбарәне истә тотып, ул аны берьюлы өч шешә алган. Әмма тәҗрибәле организм бу фикерне кабул итмәгән, өстәвенә, аракысы да ялган булып чыккан. Чаллы баһадирының бавыры моны бик авыр кичергән, тик шулай да каһарманыбыз исән калган. Тик бәхет бөтен кешегә дә елмаймый шул...


Ярославльдән килгән өч турист туган шәһәрләрендә үк такси йөртүчедән бер шешә коньяк алган булганнар, аны "бөкләгәч", Казанда реанимациягә эләккәннәр. 27 яшьлек туташны коткара алмаганнар.

Казанда бер төркем студентлар "незамерзайка" (пыяла юдырту сыекчасы) эчеп агуланганнар. Биш литрлы шешәдә ялган аракы сатып алып, аның урынына (алар бик охшаш булганнар), бутап, әлеге сыекчаны эчкәннәр. 13 кеше хастаханәгә эләккән, мәҗлестә катнашкан 20 яшьлек кыз шунда җан биргән.

Ялган аракыга каршы көрәш һич туктап тормый. Узган елның башыннан алып 200 мең литр ялган алкоголь табылып юкка чыгарылган. Ләкин бу диңгездәге тамчы гына шул. Сусаучылар булганда тәкъдим җитәрлек булачак. Федераль һәм региональ Алкоголь сәүдә үзәге кызыклы исәп ясаган. Илдә аена 15 мең сум алып яшәүче 20 миллион кеше беркайчан да кибет аракысын даими рәвештә алмаячак, аларның моңа акчасы җитмәячәк. Әгәр бу хезмәт хакына бездә 63 шешә алып була икән, Германиядә, мәсәлән, эшсезлек буенча ярдәмгә генә 200 шешә алып, чүп булганчы эчәргә мөмкин. Исәп-хисап – бер нәрсә, алкоголь бәясен беркем дә төшерергә җыенмый, әлбәттә, ә хезмәт хакын арттыру турында сөйләшеп торасы да юк.

Менә күптән түгел халык тарафыннан ихтирам ителгән эчемлекнең хакы тагын артты. Гыйнвардан бер "ярты"ның минималь бәясе 261 сум тәшкил итәчәк, ә бу сусаучылар армиясе якындагы супермаркетка түгел, ә арзанрак сыекча эзләп китәчәк дигән сүз. Тетрәндергеч статистика да, табибларның кисәтүләре дә, телевизордан күрсәтелгән ялган аракының куркынычлыгы турындагы сюжетлар да аларны куркытмый. Нәтиҗәсе бер үк булгач, нигә артыгын түләргә?

Людмила САФИУЛЛИНА



Игорь **КИЙКО**

Михаил ЛАРИЧЕВ





Герман ОГОРОДНИКОВ



• • •

Хөкүмәттә хәерчелекне ачыклаучы яңа кагыйдәләр билгелиләр: өченче категория хәерчесе, икенче һәм беренче, шулай ук "Люкс" категориялесе.

• • •

Авыл кешесе зебра сатып алган. Янына күршесе килеп сорый:

– Атланып йөреп килим әле?

– Ал, тик җайлап кына йөр, – ди хуҗа кеше.

Теге әйләнгәләп йөри дә:

– Иномарка, иномарка инде, аерылып тора! – дип зебраны мактап куя.

• • •

Тиздән "Спокойной ночи, малыши" тапшыруы НТВга күчә икән, дип сөйлиләр. Һәм хәзер Каркуша, Степашка, Хрюша үтерешләрне, көчләүләрне, курчак дөньясындагы талауларны тикшерәчәкләр.

• • •

Сатучы – кибеттәге хатынга:

– Сезгә нинди дә булса ярдәм кирәкмиме?

– Әйе, мин иң якын кешемә Яңа ел бүләге эзлим.

– Ни... бәлки, ноутбук ярар?

– Юк, минем ноутбугым бар инде.

• • •

– Сез эшәке сүзләр белән сүгенәсезме?

– Сүгенү генә түгел, мактый да беләм.

• • •

Гаражда икәү сөйләшә:

– Ничек уйлыйсың – хәзер җәйге резинаны яз көненә караганда очсызрак сатып алып буламы?

– Хәзер бөтен нәрсәне язны көткәнче арзанрак алып була!

• • •

Белдерүләрнең ешаюы һәм үҗәтлегенә караганда, ковидны чыннан да Билл Гейтс уйлап чыгарган дияргә була.

• • •

Дәвахана регистратурасында:

– Табибка тере чират беләнме?

– Вакытлыча тере.

– Сез шаяртасызмы?

– Юк, унга хәтле – тере чират, аннан соң – талон буенча.



ЯШЕРЕН КЕРЕМНӘР

Республикада үтеп киткән елда җитәкче чиновниклар арасында коррупциягә каршы законны бозу очраклары буенча өч дистәгә якын тикшерү уздырылган. 27 кеше җавапка тартылган, ә дүрт депутатны хәтта эшеннән алырга туры килгән. Халык ялчыларының сайлаучыларыннан яшерер әйберләре булганы ачыкланган. Мәсәлән, бер депутат ханым декларациясендә "КамАЗ" автомобилен саткан 250 мең сум урынына 10 мең сум күрсәткән, ә хуҗалыгындагы 4 гектар җир турында онытып җибәргән. Ә тагын ике депутат керемнәре турындагы мәгълүмат белән бүлешүдән, гомумән, баш тартканнар.

ЗАМАНЧА ИМТИХАН

Казанда бер туташ автомобиль правасына теория буенча имтихан биргәндә хокук сакчыларын ярыйсы гына куркыткан. Ул ЮХИДИ бүлегенә муенына шикле чыбыклар асып килгән. Бәладән башаяк дип уйлап, кабинетка махсус отряд чакыртканнар. Имтиханны уңышлы бирү өчен, егетләр кызыйда махсус әзерләнгән шпаргалка тапканнар. Әйтергә кирәк: бу туташ техник яктан әзерлеге буенча ялгыз түгел икән. Бу ел эчендә ЮХИДИ хезмәткәрләре имтихан бирүчеләрдә 140 шундый имтихан бирүне җиңеләйтүче җайланма тапканнар.

ГАЗ МИРАСЫ

Чаллы прокуратурасы ике йөзгә якын күп фатирлы йортта газ җиһазының нормативка караганда күпкә озаграк – 30 ел файдалануын ачыклаган. Моның өчен алты идарәче компания дисциплинар җавапка тартылган. Аларда искергән җиһазны файдалану буенча рөхсәтләре булмаган, шулай ук аларга хәтта техник диагностика да ясалмаган икән.

ХӘВЕФЛЕ ИНВЕСТИЦИЯ

Шул ук Чаллыдагы "Пятёрочка" кибете директоры матди хәлен яхшырту максатыннан кассадан 506 мең сум шудырткан. Урланган акчаны ул юк-барга тотарга теләмәгән, ә халыкара инвестиция компаниясенә урнаштырган. Ләкин полиция директор ханымга баерга бирмәгән, киресенчә – аңа карата җинаять эше кузгаткан.

ЯҢА ЕЛ ЕЛМАЮЛАРЫ









Александр ШУЛЬПИНОВ



Игорь КИЙКО



Максим СМАГИН



Михаил ЛАРИЧЕВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА

Айваз САДЫЙРОВ

QR-КОД

Фәритне эшкә кертмәделәр.

– Бүгеннән QR-код белән генә! – дип кырт кисте вахтер, маскасы астыннан мыгырдап.

Ул кайтып китте. Өйдә кимерергә кипкән балык булса да алыйм дип, кибеткә борынын тыккан иде, "QR-код!" – дип кире борып җибәрделәр.

Метрога әлеге дә баягы QR-код юклыгы аркасында эләгә алмыйча, җиде километрны җәяүләп тәпиләде.

Шактый арыган Фәритне үз фатирының ишек төбендә хатыны каршы алды:

– Өйгә QR-кодсыз аяк та атлыйсы булма!

Фәрит, аптырап, QR-код эзләргә китте. Ниһаять таптады. Өч сәгать аягүрә басып торганнан соң чират башына җитте. Көне буе ашамыйча талчыккан Фәрит бер сүзне генә әйтә алды: QR-код бирегез!

– Төп QR-кодны алыр өчен региональ QR-код кирәк! Бармы ул сездә?

Җавап бирергә Фәритнең хәле калмаган иде инде. Аның күз аллары караңгыланды, башы әйләнеп китте. Ул егылды да үлде...

"Теге дөнья. Котылдым!" – дип уйлап куйды Фәрит, үзенең үлгәнен аңлап.

Менә ул җәннәт ишекләре төбендә басып тора. Ниһаять рәхәт тормыш күрәм икән, дип куанып, алга үтте. Аны бер тавыш туктатты:

– QR-кодыгыз бармы? QR-кодсыз җәннәткә керү юк!..

Фәрит уянып киткәндә ак халатлы кешеләр, аңа игътибар бирми, чабышып йөриләр иде. Ул үзенең больницада икәнлегенә төшенә башлады.

"Димәк, мин исән?!" – дигән уй бераз гына кәефен кырды аның. Димәк, җәннәт, QR-код, егылудан соң төшләнү генә булган.

– Килегез әле монда, – дип, хәлсез генә тавыш белән медсестраны чакырып алды. – Мин кайда?

– Сез больницада. Сезне бүген үк чыгарачакбыз, – диде туташ, – барлык процедуралар үтәлгән, сезнең QR-код та бар.

– QR-код? Нәкъ шул әкәмәтнең монда керткәне исенә төште Фәритнең.

– Әйе. Барлык монда эләккән пациентларга без процедура ясыйбыз. Шуннан соң сезнең госуслугагызга автомат рәвештә QR-код килә.

Икенче көнне ул больницадан чыкты. Хастаханәнең ишек төбендә үк моны видеокамера күтәргән оператор белән кулына микрофон тоткан сары чәчле кыз урап алдылар. Фәрит аны-моны аңлашканчы, кыз бер-бер артлы сораулар яудыра башлады:

– Сез QR-код ясаткансыз икән. Ничек хәлегез? Башкаларга да тәкъдим итәсезме? QR-код ясатканчы хәлегез начар иде, хәзер бик күпкә яхшырды, шулай бит? Бу QR-код сезгә өмет күпере ролен үтәде, әйеме? Әйе, әлбәттә! QR-код уйлап табучы безнең Рәсәй галимнәре – дөньяда иң алдынгылары!

Бер-ике сүз әйтергә дип телен әйләндергәләгәнче кыз да, оператор да каядыр юк булдылар.

Ул мыштым гына өенә кайтты. Хатыны тагын кертмәс дип курыккан иде. Кертте. Менә ул тәлинкә тутырып аш состы. Тик бер сорау һаман тынгылык бирми: үзенең рөхсәтеннән башка QR-код ничек ясадылар соң аңа?

Бер читтә телевизор эшли. Экрандагы кыз:

– Илдә QR-код ясатучылар көннән-көн арта! Безнең шәһәр, тиешле 80% күрсәткечне узып, 95 кә җитте. Менә Фәрит дигән кеше үз теләге белән QR-код ясатырга килгән һәм башкаларга да тәкъдим итә.

Шулчак зәңгәр экранда Фәритнең аптыраулы кыяфәте чалынды.

– Фәрит әфәнде әйтүенчә, QR-код уйлап табучы безнең Рәсәй галимнәре – дөньяда иң алдынгылары!

Кулына тоткан кашыгын авызына алган килеш Фәрит катып калды....

Шулчак телефоны шалтырады.

– Алло!

– Фәрит Сабирҗанович, сезне федераль телеканалдан борчыйлар. Сезне ток-шоуга чакырасыбыз килә. Тапшыруның темасы: "Куар-код геройлары". Сезнең арттан машина җибәрербез.

Бердәнбер кәчтүмен киеп, Фәрит тапшыруга барып утырды. Аны мактадылар да, мактадылар. Калганнарга үрнәк итеп күрсәттеләр. Фәриткә, аптырап, башын каккалап утырудан башка чара калмады. Соңыннан тапшыруда катнашкан өчен конверт та бирделәр.

Икенче көнне Фәрит янына зур бер дәүләт газетасыннан журналист агай килеп төште. "Синең турыңда статья язабыз. Беренче биткә!"

Министрлыктан хәбәргә керделәр. Министр үзе приемга чакырган.

Кулын кысып, күкрәгенә "Атказанган QR-кодчы" медален дә тактылар.



Анатолий НЫРОВ

Фәрит геройга әверелде. Дәүләт советына да чакырдылар. Чираттагы сайлауларда депутатлыкка тәкъдим итәргә дигән сүз дә яңгырап үтте...

QR-код уйлап тапкан теге Рәсәй галимнәрен чыннан да хөрмәт итә башлады Фәрит. Менә хәзер баласы туса, мулла чакыртып, QR-код дигән исем бирер иде.

Көннәрдән бер көнне QR-кодны гамәлдән чыгардылар. Фәритне дә тиз оныттылар. Ничек тиз кабынса, шулай тиз сүнде атказанган QR-кодчының йолдызлыгы.

Икенче көнне Фәритне эшкә кертмәделәр.

– Бүгеннән эшкә QR-кодлыларны кертмибез! – дип кырт кисте вахтер!..



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

Александр БРЮХАНОВ

Ычкынды

Алсу йөзле әзмәвер, гөрселдәп, табиб каршына килеп утырды.

– Исәнмесез, доктор! Зур рәхмәт сезгә, сез чын тылсымчы икәнсез – бер атна да үтмәде, томау юкка чыкты! Хәзер мин түләүле медицинага чынлап ышана башладым... Больничныйны япсагыз да була.

– Ашыкмагыз, мондый нәтиҗәләрне алай тиз ясарга ярамый...

– Мин авыру түгел, сәламәт мин.

– Моны сез хәл итә алмыйсыз... Күзләрегез дә бик талчыккан кебек күренә... Әйдәгез, мин сезне окулистка җибәрәм...

– Сез, нәрсә, менә диган күрәм... Мине эшем көтә... Зинһар өчен, тизрәк ябыгыз шул больничныйны...

– Эш качмас ул, сезгә, бәлки, өегездә хатыныгыз белән бергә булу кирәктер? Хәзер сезне тәҗрибәле сексопатолог тикшерер, аннан соң өйгә – хәләлегез янына...

– Кирәкми, доктор, хатын минем белән болай да бик бәхетле, җибәрегез мине...

– Нишләптер, тыныч утыра алмыйсыз, бәлки, сезгә безнең проктологта каралыргадыр...

– Нинди проктолог ди ул? Бернинди дә проктолог кирәк түгел миңа!

– Холкыгыз бик шәптән түгел, ахрысы... Сезгә невропатологка күренү зыян итмәс иде...

– Юк, юк, юк... Миңа эшкә барырга кирәк.

– Күреп торам, сезгә психотерапевт кирәк – эшне чамадан тыш артык яратудан дәвалану курсы узарга!

– Кирәк түгел, – диде әзмәвер һәм торып җилкәләрен турайтты. Табиб аңа шөлләп карап куйды һәм теләмичә генә больничныйга имзасын куйды. Тегесе, шатланып, кабинеттан чыгып йөгерде.

– Их, тагын берсе ычкынды! – дип авыр сулап куйды доктор. – Мин бит аны әле ун меңлек кенә дәваларга өлгердем. Түләүле медицинаның айлык премиясен күреп булмас, ахрысы...



Александр ШУЛЬПИНОВ



Илдар НӘФИЕВ

САТЫЛУДА БЕРЕНЧЕ


Валерий ТАРАСЕНКО



Илдар НӘФИЕВ

БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Без, Ильф белән Петров кебек, бергә иҗади хезмәттәшлектә ("Чаян" битләрендә). Ә безнең кайсыбыз Ильф, кайсыбыз Петров икән соң?..

Алмаз Хәмзин: Мин – яһүд, ә син – ябрәй... Килешәсеңме?

Р. Н.: Хәзерге болганчык заманда үз хисабыңа мәчет салдыру – зур батырлык, милләтпәрвәр гамәл.

А. Х.: Байлыкның кулга керү ысулына карап салдыру – четерекле мәсьәлә...

Р. Н.: Бер дә сөртенмичә-абынмыйча сөйли белүче дикторлар – ТНВның (телевидениенең) алтын баганалары.

А. Х.: Мониторга карап йөгерек укый белүчеләрне әле алтын багана дип әйтергә кирәкмидер...

Р. Н.: Фармакологлар монополиясе тәмам котырды! Казанда чат саен – чибәр аптекалар. Ә аптекага керсәң, "тешли" торган бәяләр...

А. Х.: Менә шундый бәяләр, безне бик тә "сөя"ләр!

Р. Н.: Крокодиллар үз гомерендә тешләрен 50 тапкыр алыштыра икән. Ә безнең адәм балалары нишли – башлары, гадәттә, стоматология бүлмәсеннән чыкмый...

А. Х.: Менә кемнәрдә икән бушлай медицина!..

Р. Н.: Бер ялгыш тора-бара башка хаталарны үрчетә.

А. Х.: Безнең ил мисалында бу бик тә ачык чагыла дип әйтмәкче буласың инде, әйеме, Рашат?

Р. Н.: Замананың безнең баш очында уйнап торган чыбыркысы тузмый да, картаймый да!..

А. Х.: Каешлана гына!

Р. Н.: Әгәр Кояшны тиреслеккә этеп төшерәләр икән, ул нәҗестән дә пычранмыйча чыгачак.

А. Х.: Этүчеләре пычраначак!

Р. Н.: Сусаганны хәмер белән түгел, су белән бастыра белсәк, адәмнәр сафлыкка ирешер иде.

А. Х.: Сиңа саф түгел бу тәгълиматың...

Р. Н.: Берәү әйтә: "Мин юләр түгел, просто мин сезгә охшаган..."

А. Х.: Ике юләр килеп чыга түгелме соң?..

Р. Н.: Бу "самоизоляция" дигәнең – минем өчен тәмам Совет чорындагы иҗат йортына әйләнде!

А. Х.: Җитмәсә, әле QR-кодлы!



• • •

Авыру – табибка:

– Доктор, минем башым һәм эчем авырта.

Доктор кесәсеннән бер таблетка чыгара һәм авыруга суза:

– Уң кулдагысы – баш, сул кулдагысы эч авыртканнан. Берүк бутый күрмәгез!



Валентин ДРУЖИНИН

СССРга КУНАККА?

Утыз ел элек, 1991 елның декабрендә, Горбачёвның сәяси зәгыйфьлегеннән файдаланып, Ельцин, Кравчук һәм Шушкевич Белоруссиянең кара урманында СССРның "халыкара хокук субъект һәм геополитик берәмлек булудан туктавы" турында килешену төзеделәр.

Советлар иле дөнья картасыннан юкка чыкса да, безнең хәтердән беркая да китмәде. Ул дөреслек һәм тигезлеккә нигезләнгән яңа җәмгыять төзүнең уңышсыз талпынышы булып калды... Телчән сәясәтчеләр әлегә кадәр бәхәс алып бара: СССРны коткарып калырга була идеме һәм аны хәзер торгызырга мөмкинме? "Коткару", әлбәттә, үткәннәрдә калды, ә менә торгызу? Моның өчен ниләр эшләргә кирәклеген үзегез карагыз:

– шәхси автомобильләрнең 95 процентын, алар академиклар, артистлар һәм партия әһелләрендә генә калырлык итеп, конфискацияләргә;

– яңа йортларның 90 процентын төзелеш нормаларына туры килмәгән өчен сүтеп ташларга һәм кешеләрне агачлар арасында торган биш катлы йортларга күчерергә;

– балалар егылып төшмәсен өчен йортлардагы тәрәзәләрдә ачыла торган рамаларны томалап, форточкалар гына калдырырга;

– телевидениедә хәзерге мафияне таратып, совет чорындагы кешелекле һәм идеологик яктан дөрес тапшырулар гына калдырырга;

– хәзерге тормыш хуҗаларын икътисадый җинаятьләр өчен, утыз ел эчендә канлы тир түгеп урлаган акчаларын бюджетка кайтарып, урман кисәргә җибәрергә;

– интернетны тышкы дөньядан аерып куярга һәм ярамаган әйберләр үткәрмәү максаты белән аның эчтәлеген даими күзәтеп торырга;

– дөньяга тагын "кәҗә тоягы" күрсәтергә;

– китапларның 95 процентын түбән әхлакый эчтәлеге өчен юкка чыгарырга һәм киләчәктә бары тик сәяси тайпылышсыз, прогрессив әдәбият кына бастыру рөхсәт итәргә;

– урамнардагы бөтен плитканы куптарып алып, шома асфальт тротуарларны кайтарырга;

– елның уртача температурасын Цельсий буенча 2 градуска киметергә;

– супермаркетларда зыянлы һәм агулы матдәләр тулы азык-төлек сатуны тыярга;

– бөтен ишегалларыннан балалар мәйданчыкларын һәм тренажёрларны алып ташларга, алар урынына гадәти турникларны, футбол-хоккей мәйданчыкларын һәм домино өстәлләрен кайтарырга;

– Мәскәүдәге халыкның өчтән ике өлешен туган җирләренә кайтарып җибәрергә һәм анда завод-фабрикалар ачарга;

Уйлап карагыз, моны тормышка ашырып буламы? Безнеңчә, җавап ачыктан-ачык...



Владимир МОЧАЛОВ

ӘГӘР СИН СССРда ЯШӘМӘГӘН БУЛСАҢ...

костюм йә пальто ямауның нәрсә икәнен белмисең,

беренче карда келәм чистартканың юк,

магнитофонның тавыш алу җайланмасын одеколон белән сөртеп чистартканың юк,

газетадан телевидение программасын кисеп алып, аны кнопка белән беркетеп, стенага куйганың юк,

полиэтилен пакетлар юып киптергәнең юк,

кич саен будильник куйганың юк,

авызыңнан су бөркеп, кер үтүкләгәнең юк,

шырпыга мамык урап, колак тишеген чистартканың юк,

чәршәмбенең ашханәдә балык көне икәнен белмисең,

ертып алына торган календарьдан файдалы киңәшләр җыйганың юк,

ел саен фотоательега барып гаиләң белән фотога төшкәнең юк,

өеңдә үзең яндырып, фанера кисәгендә ясаган рәсемнәр элгәнең юк,

бөтен космонавтларны һәм Политбюро әгъзаларының исемнәрен яттан белмисең,

Калашников автоматын сүтә һәм җыя белмисең,

суыткычта ел буе Яңа ел бәйрәменә дип, тәм-том җыймыйсың...

Ә хәзер үзең дәвам ит...



ХӨКЕМ КАРАРЫ

Россия судьяларыннан закон хәрефен әдәпсез формада әйтмәүләрен сораганнар. РФ судьялар Советының этика буенча комиссиясе билгеләп үткәнчә, норматив булмаган лексика төрле дәрәҗәдәге суд кәгазьләрендә сирәк күренеш түгел, һәм хезмәттәшләренә мондый сүзләрнең рәсми документларда рөхсәт ителмәвен искәрткәннәр. Тикшерү материалларының акылсыз күчермәсе һәм хөкем карарлары эмоциональ гыйбарәләр белән бергә «флеш-суд эшчәнлеге» төшенчәсенә китергән. Әдәпсез сүзләрне лингвистик экспертиза кирәк булганда гына кулланырга мөмкин, ул вакытта да әдәплелек кысаларында булырга тиеш, сүзләр урынына «йолдызчыклар» яки күп ноктала кулланылырга киңәш ителә.

ЫЗГЫШ АСФАЛЬТЫ

Удмуртия медикларын икенче профиль буенча өстәмә эшләгән өчен җәзага тартырга җыеналар. Глазово шәһәрендә ашыгыч ярдәм бригадасы үз көчләре белән 1 нче подстанция янындагы үзләре чыга торган юлны ремонтлаганнар. Фельдшерлар иске асфальт кисәкләрен күрше ишегалдында юл чокырларын ремонтлаган эшчеләрдән алганнар. Подстанция янындагы юл ике дистә ел ремонт күрмәгән, «ашыгыч ярдәм» машиналары даими ватылып торган, шуның аркасында чакыру буенча килү вакыты да арткан. Хәзер медиклардан ни өчен муниципалитетныкы булган иске асфальтны алганга аңлатма таләп итәләр. Ә аларга ирек бирсәң, алар сменадан соң хастаханәне ремонтлап, җиһазлар да сатып алачаклар.

ӘСИРЛӘР

Ростов өлкәсенең Жирнов поселогында яшәүче пенсионер ханым газ хезмәткәрләрен кулга ала. Ике белгеч тикшерү вакытында счетчиктагы ярыкны ачыклаганнар һәм газны ябып, приборны иртәгә генә алыштырачакларын белдергәннәр. Әмма өлкән яшьтәге ханым оста булып чыга, иртәгәгә кадәр көтеп тормый, мастерларны өсләреннән биклап, яңа счетчикка китә. Кирәкле приборны ул тиз генә таба алмаган, ә белгечләрнең эш көне шулкадәр озакка сузыла ки, газчылар пленда булулары турында полициягә хәбәр итәргә мәҗбүр булалар. Әңгәмәдән соң хатын газовикларны җибәрә, ә низагны тыныч кына хәл итәләр. Счётчикны да шул ук көнне урнаштыралар.

ИМИНИЯТ ОЧРАГЫ

Читтән торып эшләүче Германия кешесе йокы бүлмәсеннән компьютерга барганда аягын сындырган, шуңа күрә иминият компаниясеннән производство травмасы өчен компенсация таләп иткән. Берничә судтан соң хезмәткәр теләгәненә ирешкән. Югары суд дәгъвачының нәкъ менә эш юлында күңелсез хәлгә эләгүен раслаган, чөнки караваттан өй офисына кадәр ераклык закон тарафыннан регламентланмаган.



ДҮРТЕНЧЕ КӨПЧӘК

Авылда Вазыйхның ихатасын табу авыр түгел иде: һәрвакыт мәңге ремонттан чыкмас трактор, өч-дүрт яньчек җиңел машина, ниндидер тимер корылмалар торган ишегалды күрсәң – димәк, бу аның йорты. Авылдашлары аңа кушамат та таккан – Ломборджини. Бөтен тирә-юньнән Вазыйх төрле тимер-томыр, иске әйберләр җыеп, эшкә ярардайларын рәткә китереп сата иде. Сатулашканда аңа тиңнәр юк, куйган бәясен бер тиенгә дә киметмәс.

Берзаман Мирзаһит сараенда тәртип урнаштырырга була. Төрле иске-москы арасыннан дүрт иске “Москвич” көпчәге дә килеп чыга.

“Боларны Вазыйхка илтеп бирергә кирәк, – дип уйлый Мирзаһит. – Ипи-сөтлек булса да акча булыр, ичмасам...”

Мирзаһит үзе ясаган арбада көпчәкләрне китергәндә, Вазыйх ярдәмчеләре белән машиналарның берсе янында маташа. Ул шунда ук “товар”ны җентекләп карап чыга, ә бераз уйланып торганнан соң ярып сала:

– Юк, бармый бу! Мин моны бушлай да алмыйм! Җәлләмичә хәзер үк чүплеккә илтеп ташласаң да була...

Мирзаһит, һич тә исе китмичә, өч тәгәрмәчне чүплеккә илтеп ташлый, ә дүртенчесен кире өенә алып кайтып, аннан хатынына чәчәкләр өчен савыт ясый. Караңгы төшкәнгә кадәр сараенда мәш килә, ә эш беткәч, калган чүпне ташларга китә.

Чүплеккә барып җиткәч, анда ниндидер шәүләләр абайлый. Тиздән тавышлар да ишетелә:

– Кара син бу Мирзаһитны! Дүртенче көпчәкне кайда куйган икән? Ярты сәгать эзлибез бит инде...

– Өч тәгәрмәч кенә сату катлаулы булыр шул. Алсалар да тиеннәр генә бирерләр!

Әлбәттә, бу ярдәмчесе белән Ломборджини иде. Мирзаһит үзалдына елмаеп куя, аларга комачауламас өчен, әкрен генә өенә юнәлә.

«Менә сиңа мә, – дип уйлап куя ул, – үзем дә белмичә, кешегә комсызлык өчен җәза биргәнмен...»

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



Александр ЛЕВИТИН

Вячеслав ШИЛОВ





Николай ЧЕРНЫШЁВ



Валерий ТАРАСЕНКО

СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

• Әгәр дә җүләр кирәк кешегә ярый белә икән, димәк, ул бөтенләй үк җүләр түгел.

• Алдынгы булам, дип, кыргыйга әверелергә дә мөмкин.

• Кеше булу гына аз, "үз кеше" дә булырга кирәк.

• Кайбер җырчылар тавышлары булмаган килеш тә җырлап-гөрләп яши.

• Эшләмичә яшәүнең дә рәтен белергә кирәк.

• Хәзер яшьләр өйләнешкәндә туй шулхәтле кыйммәткә төшә ки, аны "алтын туй" дип тә атарга була.

QR-год



Валерий ТАРАСЕНКО



Илдар НӘФИЕВ



ҮТКӘННӘРГӘ КАРЫЙК КАЕРЫЛЫП



Иван ХАНТЕМИРОВ, 1969г.

– Син кая? Шәхси чыршың бар ич!

Журналыбызның даими авторы Равил Мостафин хатирәләре (65 яше тулу уңаеннан)

"ВОБЩЕМ" ФӘИЗ

Себердә минем белән янәшә эшләп йөрүче Фәиз дигән егет бар иде. Кибеттән ипи алса да: "Вобщем, шәп булды бу", – дип кенә җибәрә. "Вообщем" сүзен кирәксә дә, кирәкмәсә дә, мулдан куллана егет.

Вахта методы белән эшләгәч, туган якларга поезд белән кайтып-китеп йөреш. Фәиз – Казан егете. Шунлыктан, бер кайтуыбызга билетларны аңа алып куярга куштык. Казан–Уренгой поездына дүрт билет, ягъни. Әлбәттә, купега инде.

Китәр көн җиткәч, Марат, Таһир һәм мин – өчәүләп Казанга юл тоттык. Чаллыдан инде. Юлда кәеф-сафа корып барырга иркенрәк булсын дип, иртәнге сигездә үк кузгалдык. Уренгойга поезд кичке сигезләр тирәсендә генә китә.

Көндезге икедә Казан вокзалында идек инде. Биштәрләрне утыргычлар астына ыргыттык та буфетка юнәлдек. Тамакны янә чылатырга исәп.

Әле Фәиз күренми. Гадәттәгечә, нәкъ вакытында гына киләчәк инде ул. Шулай булып чыкты да. Күчтәнәчләр тулы сумкаларны тотып, перронда басып торган мәлдә килеп җитте бу. Поезд кузгалырга биш-алты минут калган. Фәиз кызмача.

– Вобщем, мәгез билетларыгызны! – дип, билетларны суза.

Күрәбез: урыннар общий вагонга.

– Без бит сиңа купега алырга кушкан идек, – дибез.

– "Вобщем, купега", – дигәч, кассир шуларны бирде инде, – дип, билетларны каткат әйләндергәләп карый бу.

Нишләмәк кирәк, утырып киттек гомуми вагонга. Вообщем, Себергә, купеның җылы ятагында рәхәтләнеп ауный-ауный түгел, общий вагонның каты сәкесендә тирбәләтирбәлә барып җиттек...

РӘХМӘТКӘ АЛ ӘЛЕ

Мамадыш районының ерак бер авылында торучы бер агай шәһәргә ипи алырга китеп барган. Урман эчендәге авылына кире кайтып барышлый, бер борылышта автобустан төшеп калган да, юлдаш машиналарны туктата алмый җәфалана икән бу. Ниһаять бер миһербанлысы туктаган бит.

– Кая кайтыш, абзый? – ди икән бу.

– Рәхмәткә генә алчы, балам...


– Рәхмәткә йөртү заманнары үтте шул, абзый, – дип, шофер егет кабинасын шапылдатып япкан да, тузан туздырып китеп тә барган.

Абзый Рәхмәт Аланына кадәр җәяүләп теркелдәгән...



Эрнст ГЕЛЬМС, 1972г.


Сергей АНДРИАНОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Виталий ПОДВИЦКИЙ





• • •

Кем иртә тора, аңа төш вакытына инде мобильнигына зарядка кирәк.

• • •

– Сәлам, сердәшең ничек яшәп ята? Сезнең арагызда бит чын мәхәббәт дөрли иде...

– Бетте ул мәхәббәт.

– Аерылыштыгызмы әллә?

– Юк, өйләнештек.

• • •

Антиваксерлар, вакцина ясатканнан соң балаларыгыз булмый, дип әйтәләр. Ялган! Менә әле генә ясатып кайттым – барысы да өйдә.

• • •

Телевидение шулхәтле начар якка үзгәрде, кабызып җибәрүгә уңайсыз хәлгә каласың, әйтерсең лә акылга сай кешеләрне күзәтеп утырасың.

• • •

Хатын-кызлар үзләренең ирләрен ашатырга яраталар: табын кора, янәшәсенә утыра һәм игътибар белән иренең ашавын күзәтә. Никадәр тәмсез пешергән булса, шулкадәр ныграк йотлыгып карый...

• • •

Каргаларда да эпидемия. Иртүк "куаркуар", дип акырырга тотыналар.

• • •

Әле генә бер әбине внедорожник руле артында күрдем. Каян килгән ул аңа? Пешергәнме? Бәйләгәнме? Ә бәлки, дәваханәдәге чиратта утырып чыгаргандыр?

• • •

– Нигә синең иммунитетың шундый нык?

– Гомеремне төрле заразалар белән үткәрдем.

• • •

– Ай-яй, син нинди булган, уңган! Шулхәтле тиз үтисең эшеңне!

– Һи! Син мена аны яңадан төзәтеп эшләгәнемне күрсәң иде!

• • •

– Минем алты акыл тешемне суырдылар.

– Алар кешедә дүрттән артык түгел бугай?

– Дантист биргән счёт буенча шулай.



БӘЛА-КАЗАЛЫ БИНА

Кадерле "Чаян"! Күппрофильле Үзәк район хастаханәсенең бишенче номерлы дәвалау бинасы түбәнкамалыларга бик яхшы таныш объект. Әмма ул үзенең фидакарь табиблары яки алдынгы дәвалау ысуллары белән дан тотмый.

Бу бина хакимияттән әллә ни ерак урнашмаса да, алар тарафыннан күп еллар дәвамында игътибарга алынмый. Элек анда балалар хастаханәсе иде, янәшәсендә балалар тудыру йорты һәм репродукция үзәге эшләде. Хәзер инде моны бик өнле кешеләр яратып өлгерде – үзләренә ни кирәк, шуны ташыйлар, шау-шулы исерек төркемнәр һәм шикле затлар... Көндезен балалар куркыныч уеннар уйный, төнлә – наркоманнар һәм сукбайлар урнаша.

Бина һәр ел саен җимерелә бара, әмма аны төзекләндерергә соң түгел әле. Хәтта яшьләр үзәге ачу планнары да бар иде бугай, ләкин бу хыяллар күктә очып йөри сыман, финанслау мәсьәләсе дә каралмаган. Ныклап эшкә керешкәнче, әлеге ташландык бина зур бәла-казалар китереп чыгарырга мөмкин.

Ф. КОРБАНОВ

ТҮБӘН КАМА

ТӨЗЕЛЕШТӘГЕ ХӘЙЛӘ

Хөрмәтле редакция! Элек шундый мәзәк телдә йөри иде: әгәр кеше спорт киеме сатып алса, ул йә табигатькә чыга, йә хастаханәгә эләгә. Хәзер шуны истә тотып, байтак кешеләр спортка тартылды. "Ричмонд" торак комплексындагы Приволжский урамында яшәүчеләр – нәкъ шундыйлар.

Әле төзелеш барган вакытта ук безнең бу биләмәдә спорт тренажёрлары булачак, дип вәгъдә иттеләр. Күпләребезгә әлеге кызыксындыру чарасы моннан торак урыны сайлауга төп сәбәп булды. Чынлыкта тренажёрлар куелды, ләкин... алар әллә кайда бик еракта урнаштырылды – ябык ишегалдында түгел, ә яр кырыенда. Бар кешегә дә мәгълүм, җәмәгать урынында булган "спортзал" озак яши алмас. Ә төзүчеләр спорт мәйданының бәясе фатир хакына кертелгәнен әйткәннәр иде бит. Кызганыч, тормышта спорттагы кебек түгел – еш кына хәйләкәрләр ота...

"Ричмонд" ТК яшәүчеләр

КАЗАН







РАЗИЛ ИСМӘГЫЙЛЬ УЛЫ ВӘЛИЕВКӘ – 75!



Разил Вәлиев – танылган язучы, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. Халык аның җырларын бик яратып тыңлый, тыңлап кына калмый, отып алып, үзе дә җырлый. Татарстанның халык депутаты буларак, Разилнең һәрвакыт төпле фикере, саллы сүзе бар. Бәлки, кайчакта Разил хискә бирелеп, шагыйрьләрчә кайнарланып та киткәлидер. Әмма шунысы ачык: ул һәрвакыт бөтен җаны-тәне белән халык язмышы өчен янып яши, аның тормыш-көнкүрешен яхшырту турында кайгырта, мәдәниятебез, телебез, гореф-гадәтләребезне саклау өчен тырыша.

Минтимер ШӘЙМИЕВ.

Начар кешедән яхшы шагыйрь, яхшы язучы чыга алмый торгандыр. Разилнең шигырьләрен тыңлаганда, проза әсәрләрен укыганда мин шул турыда уйладым. Аның һәр әсәре халкыбыз язмышы өчен борчылып язылган, алар халкыбызның бәгыреннән өзелеп төшкән сыман.

Разилне мин халык язмышы өчен янып яшәүче иң фидакарь язучыларның, көрәшче егетләребезнең берсе дип саныйм.

Илһам ШАКИРОВ.

БЕЗНЕҢ ЭЗЛӘР

Безнең эзләр таралганнар иде,
Чыгып киткәч авыл капкасын.
Хәзер алар тагын тоташтылар,
Тарта торгач тормыш арбасын.

Безнең эзләр сукмакланып алда,
Зур юлларга килеп тоташты.
Ул юлларда күпләр адаштылар,
Кыйблаларын күпләр ялгышты.

Безнең эзне, сукмак-юлыбызны
Күтәреп ала шанлы мәйданнар.
Без гөрләткән данлы еллар шавын
Күкрәтсеннәр батыр дәвамнар!

Алмаз ХӘМЗИН.

Хәтерлисеңме, мәктәптә укыганда язган беренче шигырьләреңнең берсе – "Шигырь язды абзагыз"? (Зәңгәр кабырчыклар" китабы, 1968–1971 ел).

Шигырь яздым
мактап яхшы колхозны.
Тәнкыйтьчеләр тик бер карап бактылар.
"лаклаучы" дип "матур" исем тактылар.

Шигырь яздым
сүгеп начар колхозны.
Тәнкыйтьчеләр күз аттылар,
"каралтучы" исемен тактылар.
– Тормыш бит ул ала-кола, – диделәр, –
күрим дисәң, яхшы күзлек ки, – диделәр.

Хәзер инде өйрәндем:
Шигырь язам алар кушканча...
Бик начар бер колхоз алам,
башлыкларга күпме кирәк кара ягам:
ашламалар чыгарттырмыйм,
басуларны тырматтырмыйм,
яңгырларны яудырттырмыйм,
сыерларны саудырттырмыйм,
фермаларны җимерттерәм,
атларына коры улак кимерттерәм.

Бер сүз белән – бөтенесен тилмерттерәм.
Һәм шуннан соң
бер бик яхшы председатель
китерттерәм,
ярты елда шул колхозны
бер гасырга сикерттерәм,
Сәләхине, Лотфыйларны
Тук тормыштан кикерттерәм.
Иң азактан – җитәкчегә
бик зур бүләк бирдерттерәм.

Тәнкыйтьчеләр,
менә монысын карагыз:
тешегезне сындырырлык
шигырь язды
абзагыз!

Аннан соң, туган авылыбыз Ташлыкка багышлап, бик матур гына җыр да иҗат иттек. Сүзләре синнән булды, көе – миннән.

ТАШЛЫК АВЫЛЫ ҖЫРЫ

Урманнарга барган идем,
Каршы алды имәннәр.
Урман кебек шаулап яши
Туган ягын сөйгәннәр.

Кушымта:
Туган аулым Ташлык –
Минем җаныма башлык.
Ташлап китмәм ташкалага,
Мин бит Ташлыкка гашыйк.

Зәй буена төшкән идем
Колач җәеп йөзәргә,
Безнең яктан матур җир юк, –
Ышан минем сүзләргә.

Кушымта.
Кайнар тауга менгән идем,
Аякларны пешерә.
Җаннары таш булмаганнар
Безне искә төшерә.

Бу җыр хәзер Сабантуйларда безнең авылның гимны булып яңгырый.

Юбилееӊ уңаеннан, шагыйрь дусларыңа багышланган эпиграммаларыңның берничәсен тәкъдим итәбез.

РАБИТ БАТУЛЛАГА

Театрлар гримыннан
Буялып калган мыек
Миңа һаман ирек бирми
Әдип дияргә, кыен.

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВКӘ

Тыйнак булдык – күрмәделәр,
Усалландык – багалар.
Ышанмасаң, укып кара:
Шәп бит: "Карап багалар",
Шәп бит: "Кара, багалар",
Шәп бит: "Кара баганалар"...
Уф, үзем дә көчкә әйтәм:
Шәп бит: "Кар абагалар!"

ШАГЫЙРЬ ДУСКА

Табыннарны онытып тор, –
Поэзиягә табын!
Табыннар сиңа табыныр
Чыккач шигырь китабың...

Миңа берне чәпемәгән,
чәпим әле үзенә:
Төрттереп язу килешмәс,
Шундый дустым-шагыйрьгә...
Ул миңа гына дус түгел,
Дус ул хәтта Шәймигә!



Башы. Ахыры 18 нче биттә.

Разил Вәлиевнең үткен телле, җор сүзле, тапкыр, шаян икәнен мин генә түгел, күпләр белә.

ТУЙДЫРА АЛМАДЫ

Шулай берчакны "Татарстан яшьләре" газетасыннан Разилгә шалтыратканнар. Тиз генә Рабит Батулла пьесалары турында рецензия-мәкалә язып китерүне сораганнар. Күләме күпме кирәк дигәч: "Безнең формат бәләкәй, никадәр кыскарак булса, шулкадәр яхшы", – дигәннәр.

Икенче көнне Разил редакциягә мәкаләсен тотып килеп тә җиткән. Укып карасалар, мәкаләдә бер җөмләдән генә торган мондый сүзләр язылган ди: "Рабит Батулланың күпсанлы бик әйбәт пьесалары төрле сәхнәләрдә кат-кат куелып, халыкны туйдырып бетерсә дә, үзенең тамагын туйдыра алмады".

ЯРЫЙ ӘЛЕ ХАТЫН АЛМАГАН

Композиторлар, җырчылар, шагыйрьләр, җыелышып, зур мәҗлес ясаганнар. Фасил Әхмәтнең гонорар алган чагы икән, мәҗлес чыгымнарын күбрәк ул күтәргән.

Икенче көнне уянгач, Фасил Әхмәт Разил Вәлиевкә шалтырата икән: "Карале, дустым, кичә минем кесәдә 25 тәңкә калган булырга тиеш иде, эзлим-эзлим, шуны таба алмыйм..." Аңа каршы Разил Вәлиев: "Фасил абый, мәҗлес азагында син аңа шампанский китерттең бит", – дигән. Бу сүзләрне ишеткәч, трубкада Фасилнең җиңел сулап куйганы ишетелгән: "Ә мин монда хатын алган микән әллә дип кара кайгыга калган идем. Ярый, алайса, әйбәт булган, әрәмгә китмәгән. Юкса хатын алса, суларга салган кебек булыр иде бит", – дигән ул.

ЯЗА ТОРГАН АЯК

Разилнең бер каләмдәше бозда таеп егылып, аягын сындырган. Күчтәнәчләр күтәреп, Разил моның янына килгән. Дусты сөенгән, рәхмәтләр әйтә-әйтә, титаклап озата чыккан. Саубуллашыр алдыннан Разил моннан сорап куйган: "Халат эченнән күренми, кайсы аягың сынды соң синең?" "Сул аяк сынды, иң кирәклесе", – дигән дусты. "Бигрәкләр яза торган аягың булган икән шул. Ярый, тизрәк төзәлсен инде", – дип, дустын юата-юата саубуллашып чыгып киткән Разил.


ТАМЧЫ ДА ҮЗГӘРМӘГӘНСЕҢ

Разил Вәлиев, озак еллар күрмичә торган дустын очраткач, колачын җәеп: «И дустым, күпме гомер үтеп, син тамчы да үзгәрмәгәнсең!» – дип эндәшкән. Бу сүзләрне «бер дә картаймагансың» дигән мәгънәдә аңлап, мактау буларак кабул иткән дусты, авыз тутырып елмая. Шулчак Разил тагын өстәп куя: «Яхшы якка үзгәрмәгәнсең, дип әйтәм...» Дустының елмаерга дип җәелгән авызы аптыраудан ачык килеш калган.

Ә без, "Чаян" журналы редакциясе хезмәткәрләре, күренекле язучыбыз Разил Вәлиевкә сәламәтлегенең һәм иҗатының гел яхшы юнәлешкә омтылуын теләп калабыз!



Валерий ТАРАСЕНКО



Валентин ДУБИНИН



Ринат МИРЗАЯНОВ



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 1 (1914) гыйнвар 2022

Баш редактор: Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде. Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.


«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 28.12.2021 ел.
Тираж – 3373 Заказ Е-4261

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Кеше оча аламы?
2. Эшендәге үсешеңә этәреш ясаучы шарт нәрсә ул?
3. Авызда ничә теш булырга тиеш?
4. Ни өчен хәзерге укучылар, аркаларына бик күп дәфтәр һәм китаплар тутырып, алагаем биштәр күтәреп йөриләр?
5. Джинсы чалбарлардагы кечкенә кесә нәрсәгә кирәк?
6. Сырдагы пальма маеның барлыгын ничек ачыкларга?
7. Яңа ел өстәленең төп ризыгы.

ҖАВАПЛАР

1. Ала, ләкин аска таба гына. 2. Эшендә хезмәт хакын арттырмыйча, бурыч-йөкләмәләреңне күбәйтү. 3. Аларны дәвалап, саклап тота алган хәтле. 4. Мәктәп аларны яшьтән үк өйгә ашамлык китерүчеләр итеп тәрбияли. 5. Хезмәт хакыңны салып куяр өчен. 6. Әгәр сырны трактор белән таптатсалар, ул – чыны була. Әгәр инде аны кибеттә сатсалар, анысы пальмалы сыр. 7. Инфляция.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 12 нче санындагы чаянвордның тикшерү сүзе – **«ЯШЬЛЕГЕМ ХИСЛӘРЕ».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Р. ГЫЙЛӘҖЕВА (Чаллы),
А. СӘЙФУЛЛИН (Алабуга),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.).

Җиңүчебез – Чаллыдан

Раушания ГЫЙЛӘҖЕВА

Александр АЛЁШИН



Нәкъ бер елдан «Чаян» журналына 100 ел була. Ә аның баш рәссамы Александр Алёшинның редакциядә эшли башлавына 27 ел тула. Ерак 1984 елда ук ул анда беренче рәсемен бастыра. Ә аннан аларның күпме булганын ул үзе дә хәтерләми... Карикатуралардан тыш, журнал битләрендә Александрның ике йөздән артык шаян дүртьюллыгы дөнья күрә. Ә бүген Александр «Чаян» укучыларына үзенең вернисажын тәкъдим итә.







4612750670080